| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

№ 162/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

« 26 » 10 2021

Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирүгә дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламент раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы, «Федераль милектәге су объектларында ясалма җир кишәрлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирүгә дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кушымтада бирелә торган административ регламентны расларга.

2. Юридик бүлеккә, дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына бу боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынган вакыттан ун эш көне эчендә аның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирүгә дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламент раслау турында» 2020 елның 11 ноябрендәге 182/о номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр М.М.Айзатуллин

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 26 октябрендәге 162/о номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирүгә дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламент**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирүгә дәүләт хезмәте күрсәтү буенча әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

Әлеге Регламентта шулай ук административ процедураларның вакытлары һәм эзлеклелеге, вазыйфаи затлар белән ике арадагы хезмәттәшлек тәртибе билгеләнә.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, физик затлар, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итүче шәхси эшкуарлар, юридик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче) ясалма җир кишәрлекләрен булдыруның инициаторлары булып торырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче исеменнән юридик зат җитәкчесе яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат ышаныч кәгазе яисә үзенең шәхесен таныклаучы документлар нигезендә эш итә.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт хезмәтен башкаручы: Министрлыкның социаль-мәдәни объектлар төзү бүлеге (алга таба – Бүлек).

1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 10.

Бүлекнең урнашкан урыны: Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 10 йорт, 4 нче кат, 405 нче каб.

Министрлыкның эш графигы: дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

Гаризалар кабул итү графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.

«Кремль» тукталышына кадәр җәмәгать транспортында 98 номерлы автобус белән килергә; «Университет» туктатылышына кадәр:

8, 10, 10а, 30, 35, 54, 63, 91, 99а номерлы автобуслар;

7, 17, 20, 21 номерлы троллейбуслар.

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә башкарыла.

1.3.2. Бүлекнең белешмә телефоннары: 231-14-57, 231-15-02.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://www.minstroy.tatarstan.ru, электрон почта адресы: msagkh@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында, шулай ук Бүлек урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша;

Министрлыкның рәсми сайтында;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatar.ru/) (алга таба – Республика порталы);

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) (алга таба – Хезмәтләр күрсәтү реестры реестры);

3) Министрлыкка телдән (шәхсән яки телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә);

5) «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесенә һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең (алга таба – күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны) ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткән очракта (шәхсән яисә телефон буенча).

1.3.5. Министрлыкның урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайтының адресы, шулай ук электрон почтасы, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарының урнашкан урыны һәм эш графигы турындагы мәгълүмат Бүлек хезмәткәре тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, Хезмәтләр күрсәтү реестрында һәм Республика порталында урнаштырыла. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламент (белешмәлек) кушымтасында китерелгән.

Мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчасында) булган дәүләт хезмәте күрсәтүтурындагы белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив-хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Министрлыкның рәсми сайтында, Хезмәтләр күрсәтү реестрында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәк – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торган), «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

КФҮ АМС – күпфункцияле үзәкләр эшчәнлегенә ярдәм итүнең автоматик мәгълүмат системасы;

«бер тәрәзә» принцибы – дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле мөрәҗәгать белән яки 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгать белән бер мәртәбә мөрәҗәгать иткәннән соң гамәлгә ашырыла торган, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар белән хезмәттәшлек итү мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актларга һәм хезмәттәшлек итү турында килешүгә туры китереп күпфункцияле үзәк аша гамәлгә ашырыла торган принцип;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 3 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирү

2.2. Башкарма хакимият органының атамасы

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар;

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә Министрлыкта яки күпфункцияле үзәктә кәгазь чыганакта, мөһер белән таныклап һәм Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты яисә күпфункцияле үзәк хезмәткәре имзасы белән раслап бирелә. Мөрәҗәгать итүче таләбе буенча документның кәгазь нөсхәсе белән берлектә, мәгълүматның күчмә чыганагына яздырып яки электрон документ нөсхәсен мөрәҗәгать итүченең электрон почта адресына электрон документ формасында, мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул белән (почта буенча, электрон почта адресына) җибәреп, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документн нөсхәсе бирелергә мөмкин.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Ясалма оештырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту процедурасын гамәлгә ашыру вакыты гариза һәм документлар Министрлыкка алынган көннән башлап ун календарь көн тәшкил итә.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.4.3. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән, шул исәптән электрон документ формасында, бирү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны

тапшыра:

Ясалма оештырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү турында гариза. Гариза формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән;

Мөрәҗәгать итүченең яисә мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен таныклый торган документ (Министрлыкка, күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта күрсәтелә).

Дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, аның вәкаләтләрен раслый торган документ.

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

1) ясалма җир кишәрлеген кабул итү акты (объектны эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирүгә мондый акт тапшыру Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракта);

2) ясалма җир кишәрлегенең техник регламентлар таләпләренә туры килүен раслый торган һәм аны төзүне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан имзаланган документ;

3) ясалма оештырылган җир кишәрлеге параметрларының проект документларына туры килүен раслый торган һәм аны төзүне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан имзаланган документ.

2.5.2. Ясалма җир кишәрлеге булдыруга рөхсәттә шулай ук мондый ясалма җир кишәрлегендә бер яки берничә капиталь төзелеш объектын да төзү каралган булса, бер үк вакытта ясалма булдырылган җир кишәрлеген һәм анда урнаштырылган капиталь төзелеш объектын эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирелә.

Шул ук вакытта капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт алу өчен түбәндәгеләр таләп ителми:

1) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар;

2) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы.

2.5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар бер нөсхәдә (төп нөсхәсе яисә күчермәсе) яисә ике нөсхәдә тапшырыла, аның берсе – төп нөсхә, икенчесе мөрәҗәгать итүче яисә төзүче тарафыннан таныкланган күчермә булырга тиеш. Документлар ике нөсхәдә тапшырылган очракта, тикшерүдән соң төп нөсхәсе мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелә. Документларның оригиналларын тапшыру мәҗбүри түгел.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);

почта аша.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм теркәлә торган документларны күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче гариза белән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдалану-

дагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре яки Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша да тапшырырга (җибәрергә) хокуклы.

Ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт алуга кирәкле документлар бары тик электрон формада гына, техник мөмкинлек булган очракта, тапшырыла:

әгәр капиталь төзелеш объектының проект документларына экспертиза буенча уңай бәяләмә (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $12^1$ өлешендә каралган очракта, аерым төзелеш этапларына карата), РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының $3^4$ өлешендә каралган очракларда проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 6 өлешендә каралган очракларда, проект документларына дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе электрон формада тапшырылган булса;

әгәр капиталь төзелеш объектына проект документлары һәм (яисә) мондый проект документларын әзерләү өчен башкарылган инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре, шулай ук проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздыру өчен кирәкле башка документлар электрон формада тапшырылган булса.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

Министрлык тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түбәндәге документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) соратып алына:

1) «Федераль милектәге су объектларында булдырылган ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 246-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясында күрсәтелгән очракта, ясалма җир кишәрлеге оештыру буенча эшләр уздыруга рөхсәт яисә капиталь төзелеш объекты төзүгә рөхсәт;

2) ясалма булдырылган җир кишәрлегенең проект документларына туры килүе турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы бәяләмәсе, дәүләт экологик күзәтчелек бәяләмәсе.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга мөмкин булган документларны мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә дә тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре юк.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

2.8.2. Ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт сорап мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) әлеге Регламентның 2.5.1 пунктында күрсәтелгән документларның булмавы;

2) ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлегенең ясалма җир кишәрлеген булдыру буенча эшләр уздыруга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве;

3) ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлегенең параметрлары проект документациясенә туры килмәве.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар, сәбәпләрен күрсәтеп, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне, аның ихтыярына карап, мөрәҗәгать

итүчегә яки күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте күрсәтү түләүсез нигездә башкарыла.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан чират көтүнең максималь вакыты унбиш минуттан артык булырга тиеш түгел.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада

2.13.1. Күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гариза вазыйфаи инструкция нигезендә гариза гаризаны кабул итү һәм теркәүне гамәлгә ашыручы күпфункцияле үзәк хезмәткәре (алга таба – күпфункцияле үзәк хезмәткәре) тарафыннан алынган көнендә теркәлә.

Гаризаны һәм теркәлә торган документларны Министрлык белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Министрлыкка тапшыру тәэмин ителә.

Күпфункцияле үзәк аша килгән гариза һәм теркәлә торган документлар Министрлыкта алынган көнендә теркәлә.

2.13.2. Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза гариза алынган көнне теркәлә. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү

өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү максатларында, шул исәптән объект хезмәткәрләре ярдәме белән дә, бүлмәләр буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

3) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

4) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

5) инвалидларның хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү;

7) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, озата йөри торган этне кертү;

9) дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңәргә ярдәм итү.

Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларга һәм әлеге пунктның 3-6 пунктчаларында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә керең эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәте күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплексы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма

хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтен (шул исәптән тулы күләмдә) күрсәтә алу мөмкинлеге яки андый мөмкинлекнең булмавы

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документлар кабул итеЛә, бирелә торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итеЛә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

3) Министрлык хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Регламент бозылуга карата нигезле шикаятьләрнең булмавы;

4) мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлек итү саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Министрлык яки күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре белән үзара хезмәттәшлек итүе түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

барлык кирәкле документлар белән гариза тапшырылганда, – бер тапкыр;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь чыганакта алган очракта, бер тапкыр.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә үзара хезмәттәшлек итүнең вакыт озынлыгы унбиш минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын күчмә радиотелефон элемтәсе чаралары ярдәмендә бәяләргә хокуклы.

2.15.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкта, күпфункцияе үзәктә алынырга мөмкин.

2.15.4. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

2.16.1. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.16.2. Гариза һәм документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә квалификацияле электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карау;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү);

6) техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны төзү һәм документларны рәсмиләштерү өлешендә дә

3.2.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүе административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып түбәндәгеләр тора:

мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә – күпфункцияле үзәк хезмәткәре;

мөрәҗәгать итүче Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә – Министрлык бүлеге белгече.

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация сорап, күпфункцияле үзәккә шәхсән үзе һәм телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә дә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәкнең рәсми http://mfc16.tatarstan.ru/ сайтыннан алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә консультацияләү.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка телефон һәм электрон почта буенча мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы турында һәм

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча да консультация алырга хокуклы.

Бүлек хезмәткәре мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә консультацияләү.

3.3. Мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карау

Мөрәҗәгать итүче гаризаны шәхсән үзе, ышанычлы заты аша, почта, электрон почта буенча, күпфункцияле үзәк аша тапшыра ала.

3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны күпфункцияле үзәк аша яки күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша кабул итү.

3.3.1.1. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

3.3.1.2. Гаризаларны кабул итүче күпфункцияле үзәк хезмәткәре:

мөрәҗәгатьнең предметын билгели;

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый;

документлар тапшыручы затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү буенча язу бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: җибәрүгә әзер гариза һәм документлар пакеты.

3.3.1.3. Күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән документлар пакетын мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән көннән башлап бер эш көне эчендә Министрлыкка тапшыра.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: Министрлыкка юлланган гариза һәм документлар пакеты.

3.3.2. Министрлык тарафыннан документлар комплектын карау.

3.3.2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларның алынуы административ процедура үтәлешен башлау нигезе булып тора.

3.3.2.2. Мөрәҗәгать итүче гариза белән министрлыкка мөрәҗәгать иткән очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

мөрәҗәгатьнең предметын билгели;

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;

документлар тапшыручы затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә (документларның күчермәләренең тиешенчә рәсмиләштерелүен, документларда чистартылган, өстәп язылган, сүзләре сызылган урыннарның һәм алдан сөйләшенмәгән башка төзәтү урыннарының булу-булмавын) туры килү-килмәвен тикшерә;

алынган документларны Министрлык Бүлегенең дәүләт хезмәте күрсәтү вазыйфасы йөкләнгән вазыйфаи затларына (алга таба – Бүлек белгечләре) карау өчен тапшыра.

Документлар карау өчен алынганнан соң, Бүлек белгече:

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры китереп, тапшырылган документларның комплектлылыгын тикшерә;

алынган документларны өйрәнә.

3.3.2.3. Әлеге Регламентның 3.3.2 пунктында билгеләнә торган административ процедуралар гариза карау өчен алынган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, карау өчен кабул ителгән документлар комплекты.

3.3.2.4. Бүлек белгечләре ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирү турындагы гаризаларны теркәү журналын (алга таба – Журнал) алып бара.

Журналда түбәндәгеләр күрсәтелә:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тапшырылу датасы (Министрлыкка килү датасы);

мөрәҗәгать итүченең атамасы;

документларны кабул иткән Министрлыкның структур бүлекчәсе вазыйфаи затының фамилиясе һәм инициаллары;

объектның атамасы һәм алынган документларның (папкаларның, тартмаларның һ.б.) кәгазьләр саны;

ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт әзерләү датасы;

мөрәҗәгать итүчегә ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт (ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат) тапшыру датасы яки почта аша җибәрү датасы;

ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт (ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат) алган затның имзасы;

искәрмә.

Журнал кулдан язып һәм электрон формаларда, әлеге Регламентның 2 нче кушымтасына ярашлы рәвештә алып барыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Журналдагы язу.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү

3.4.1. Министрлыкның ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи заты, әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыра һәм

ведомствоара электрон багланышлар системасы аша (техник мөмкинлек булмаса – башка ысуллар белән) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар гариза карау өчен кабул ителгән көнне башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: хакимият органнарына һәм (яки) хакимият органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларга җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша (техник мөмкинлек булмаса – башка ысуллар белән) килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр (алга таба – документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура законнарда билгеләнгән чорларда гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар (белешмәләр), яисә баш тарту турында ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка юлланган белдерү.

3.4.3. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи зат ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша (техник мөмкинлек булмаса – башка ысуллар белән) соратып алына торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне) яисә, документ һәм (яки) мәгълүмат булмаса, баш тарту турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедура ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча белешмәләр алынган көнне үтәлә.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: Министрлыкка җибәрелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар (белешмәләр) яисә, документ һәм (яки) мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту турында белдерү.

3.4.4. Әлеге Регламентның 3.4.1, 3.4.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, шул исәптән гаризаны теркәгән вакыттан башлап, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар җыелмасын карый;

әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре ачыкланса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты әзерли;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре буенча ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплутациягә кертүгә рөхсәт проекты әзерли;

әзерләнгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе проектын билгеләнгән тәртиптә килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты, ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплутациягә кертүгә рөхсәт проекты.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын, ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплутациягә кертүгә рөхсәт проектын (алга таба – документларның проектлары) килештерү һәм имзалау дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, министр урынбасары, министрның беренче урынбасары тарафыннан башкарыла.

Документларның әзерләнгән, кисәтүләре булган проектлары эшләп бетерү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи затка кире кайтарыла. Кисәтүләре бетерелгәннән соң, документларның проектлары янә килештерү һәм имзалау өчен җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар, ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплутациягә кертүгә рөхсәт.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү)

3.6.1. Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат:

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен теркәүне тәэмин итә;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм Министрлыкта яисә күпфункцияле үзәктә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар, дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документ имзаланганнан соң, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларын үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.

3.6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе:

3.6.2.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе өчен күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә бирә. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча, кәгазьдәге документ нөсхәсе белән берлектә, алына һәм куела торган мәгълүмат чыганагына яздыру юлы белән яки электрон документ нөсхәсен мөрәҗәгать итүченең электрон почта адресына җибәрү юлы белән, аңа электрон документ нөсхәсе бирелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне күпфункцияле үзәкнең эш регламентында

билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирүне күпфункцияле үзәк хезмәткәре тарафыннан Автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәве, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.6.2.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә, документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь чыганакта тапшыра. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча, кәгазьдәге документ нөсхәсе белән берлектә, алына һәм куела торган мәгълүмат чыганагына яздыру юлы белән яки электрон документ нөсхәсен мөрәҗәгать итүченең электрон почта адресына җибәрү юлы белән, аңа электрон документ нөсхәсе бирелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне, Министрлыкның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат) тапшыру.

Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы булган вазыйфаи зат тарафыннан кулдан һәм электрон формаларда әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге оештырылган очракта, ясалма җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен бирелгән рөхсәтләр реестры алып барыла.

3.7. Техник хатаны төзәтү

3.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата булуы ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлыкның Министрлыкка алына торган корреспонденцияне теркәү өчен җаваплы булган документлар үтәлешен тикшереп тору бүлегенә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 4 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан Министрлыкка яки күпфункцияле үзәккә шәхсән тапшырыла яисә почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә дә) җибәрелә.

3.7.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, гаризаны теркәлгән документлары белән бергә терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.7.3. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү

нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны башкара һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып калып тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша, Бүлеккә техник хатасы булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Техник хатасы булган документ мөрәҗәгать итүчегә электрон формада бирелгән булса, Бүлек белгече төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып тапшыра яисә, бу хакта гаризада күрсәтелгән булса, электрон документ формасында җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан гариза алынганнан соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвен һәм башкаруын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы тикшереп тору тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм Төзелеш комплексын үстерү идарәсе җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Агымдагы контрольлек Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең Министрлыктагы вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү.

Административ процедураларның үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү Министрлык актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.8. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне һәм шикаятьләрне судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәре, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сәбәпле министр тарафыннан кабул ителгән карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына яисә монополиягә каршы органга белдерелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә, күпфункцияле үзәк җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту очрагында, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатып торылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында туктатып тору нигезләре каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан, Республика порталыннан, Бердәм порталдан файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында да кабул итеп алынырга мөмкин.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта буенча, «Интернет» челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Республика порталыннан, Бердәм порталдан файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән

документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең яки хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны яисә мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр. Шулай ук мөрәҗәгать итүчегә җавап бирелергә мөмкин булган элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) яисә почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр.

5.6. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча, Мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать

итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.9. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирүгә дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентка 1 нче кушымта

Форма

кемгә: Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына
кемнән: ____________________________________________
(төзү, капиталь ремонтлау яки үзгәртеп коруны гамәлгә ашырырга планлаштыра торган юридик зат – төзүченең атамасы;
____________________________________________
ИНН; юридик яисә почта адресы;
____________________________________________
җитәкчесенең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта), телефоны, банк реквизитлары (банк атамасы, исәп-хисап счеты, к/счеты, БИК)

**Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирү турында гариза**

Ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирүегез турында үтенәм ____________________________________________
(объект атамасы)
түбәндәге адрес буенча урнашкан җир кишәрлегендә: ____________________
____________________________________________
(шәһәр, район, урам, кишәрлек номеры)

Ясалма рәвештә җир кишәрлеген булдыру буенча эшләрне уздыру ____________________ «____»____________________ ел, №__________ нигезендә гамәлгә ашырылды.
(документ исеме)

Җирдән файдалану хокукы беркетелгән ______________________________
____________________ «____»____________________ ел, №______________.
(документ исеме)

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез:

ясалма җир кишәрлеген оештыру эшләрен финанслау түбәндәгечә гамәлгә ашырылды ____________________________________________
(банк реквизитлары һәм счет номеры)

Эшләр подряд (хуҗалык) ысулы белән уздырылды, түбәндәге килешү нигезендә: «____»______________20_____ел. № ____________________

______________________________________________________________________
(оешманың атамасы, ИНН, юридик һәм почта адреслары, җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта),

______________________________________________________________________
телефоны, банк реквизитлары (банк атамасы, исәп-хисап счеты, к/счеты, БИК)

Эшләрне башкару хокукын беркетү нигезе:___________________________

______________________________________________________________________
(документ исеме һәм аны биргән вәкаләтле оешманың атамасы)

_________________________ «____»_______________________ ел, №_______________.

Эшләрне башкаручы итеп ______________ «____»____________ ел, № ______боерык нигезендә ____________________ билгеләнде, ул __________ махсус

(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме) (югары, урта)

белемгә ия һәм төзелештәге эшләү стажы ___ ел.

Төзелеш контрольлеге «___»________ ел, № ______________ килешү нигезендә түбәндәге тарафыннан гамәлгә ашырылды:

______________________________________________________________________
(оешма атамасы, ИНН, юридик һәм почта адреслары, җитәкченең ФИА (соңгысы булган очракта), телефон номеры, банк реквизитлары (банк атамасы, и-х/сч, к/сч, БИК)

______________________________________________________________________

заказчы (төзүче) функцияләрен башкару хокукы беркетелгән_______________

______________________________________________________________________
(документ исеме һәм аны биргән оешма атамасы)

_________________________ «____»____________________ ел, №______________.

Әлеге гаризада китерелгән барлык белешмәләргә бәйле барлык үзгәрешләр хакында Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына хәбәр итү бурычын үз өстемә алам.

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | __________________ | ______________________ |
| (вазыйфа) | (имза) | (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) |

«____»_______________20_____ ел.
Мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирүгә дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентка 2 нче кушымта

## Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирү турында гаризаларны теркәү журналы

| Тәртип саны | Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тапшырылу датасы (Министрлыкка килү датасы) | Мөрәҗәгать итүче | Документларны кабул иткән вәкаләтле структур бүлекчәдәге вазыйфаи затның фамилиясе һәм инициаллары | Объектның атамасы һәм алынган документларның (папкаларның, тартмаларның һ.б.) кәгазьләр саны | Ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт әзерләү датасы; | Ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәтне мөрәҗәгать итүчегә тапшыру датасы; | Ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт (ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат) алган затның имзасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирүгә дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентка 3 нче кушымта

Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен бирелгән рөхсәтләр реестры

| Тәртип саны | Алынган документның номеры һәм датасы | Мөрәҗәгать итүче | Объектның исеме | Рөхсәт датасы һәм номеры | Рөхсәтнең гамәлдә булу чоры | Җибәрелә торган документның номеры һәм датасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирүгә дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентка 4 нче кушымта

кемгә: Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына

кемнән: ____________________

*(төзелешне, капиталь ремонтны яки үзгәртеп коруны планлаштыручы юридик затның исеме; ИНН; юридик һәм почта адреслары; җитәкчесенең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта); телефоны; банк реквизитлары (банк исеме, исәп-хисап счеты, к/счеты, БИК)*

____________________

____________________

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

____________________

*(бирелгән документ)*

____________________

Болай дип күрсәтелгән:

____________________

Дөрес белешмәләр:

____________________

Техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Документның әзер булуы турында миңа түбәндәгечә хәбәр итүегез турында үтенәм ____________________

____________________

*(хәбәр итү ысулы)*

| | | |
|---|---|---|
| ____________ | ____________ | ____________ |
| *(вазыйфа)* | *(имза)* | *(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))* |

«___» ____________20_____ел.

*Мөһер урыны* (булган очракта)

Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирүгә дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентка (белешмәлек) кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы хакимият органнары (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар**

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министрның беренче урынбасары | 231-14-03 | Aleksey.Frolov@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 231-14-05 | Ilshat.Gimaev@tatar.ru |
| Төзелеш комплексын үстерү идарәсе җитәкчесе | 231-17-08 | Dinar.Sagdatullin@tatar.ru |
| Социаль-мәдәни объектлар төзелеше бүлеге җитәкчесе | 231-14-57 | Dmitriy.Yasakov@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестицияләү программаларын гамәлгә ашыру бүлеге җитәкчесе | 264-77-24 | Yuriy.Azin@tatar.ru |